Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары
(мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 9 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 60 минут.
Максималь балл – 44.

I. Теоретик биремнәр. (9 балл)

1. Матур әдәбиятка хас төп өч сыйфатны аерып билгеләгез һәм язып куегыз. (6 балл)

2. Түбәндә аталган әсәрләрнең кайсылары гомумтөрки әдәбиятка карый. (3 балл)

А) Күлтәгингә багышланган каберташ язмасы
Б) “Идегәй”
В) “Диване лөгатет-төрк”
Г) “Җил иясе җил чыгара”
Д) “Котадгу белек”

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (20 балл)

1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә геройларның эш-гамәлләре аша нинди сыйфатлар хуплана, ниндиләре тәнкыйтьләнә, кире кагыла? Аерып куеп, санап чыгыгыз. (10 балл)

2. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

3. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә автор идеалын чагылдырган геройның исемен яки исемнәрен атагыз. (5 балл)

III. Иҗади эш. (15 балл)

Соңгы елларда киң кулланылышта булган *компьютер, ноутбук, телефон, планшет, телевизор* турында 5 мәкаль уйлап чыгарып языгыз.